КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 октябрь г.Казань № 1249

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» процесслы чаралар комплексын гамәлгә ашыру турында» 2008 ел, 28 март, 201 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» процесслы чаралар комплексын тормышка ашыру турында» 2008 ел, 28 март, 201 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 август, 740 нчы; 2016 ел, 27 декабрь, 1005 нче; 2018 ел, 26 февраль, 120 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 915 нче; 2023 ел, 23 март, 329 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фондына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» процесслы чаралар комплексын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында дәүләт торак сертификатларын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенең 3 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин